КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 8 февраль г.Казань № 66

Баулы муниципаль районында җир кишәрлекләрен бер категориядән икенче категориягә күчерү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының, «Татойлгаз» АҖнең Баулы муниципаль районында урнашкан, дәүләт милкендә булган 1,4111 гектар гомуми мәйданлы авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җир кишәрлекләрен түбәндәге кадастр саннары белән Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтәләрдә күрсәтелгән чикләрдә җир асты байлыкларыннан файдалану максатларында сәнәгать җирләре һәм башка махсус әһәмияттәге җирләр категориясенә күчерү турындагы тәкъдимен кабул итәргә:

| Җир кишәрлегенең кадастр саны | Мәйданы, гектар |
|---|---|
| 16:11:080701:492 | 0,7711 |
| 16:11:080701:493 | 0,64 |
| Барысы | 1,4111. |

2. Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына билгеләнгән тәртиптә тиешле үзгәрешләр кертергә тәкъдим итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин